РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«17» сентябрь 2021 г. г. Альметьевск № 58

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмә хакында» 2018 елның 31 маендагы 244 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 343 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 40 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарга 1 нче кушымтаның «Район башкарма комитеты вәкаләтләре» 2 бүлегендә:

1.1.1. 2.2 пунктындагы 11 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2.3. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне хәл итүгә район Башкарма комитетының хокуклары:»;

1.1.2. 2.3 пунктын 2.4 пункты дип санарга;

1.2. Карарга 1 нче кушымтаның “Район башкарма комитеты җитәкчесе” 3 бүлегендә:

1.2.1. 3.4 пунктын түбәндәге эчтәлекле сүзләр белән тулыландырырга:

«,«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән».»;

1.2.2. 3.10 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) Россия Федерациясе гражданлыгы яки чит ил гражданлыгы-Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы, чит дәүләт гражданлыгы булу яисә яшәү хокукы яисә Россия Федерациясе халыкара

Заказ № 2625

шартнамәсе нигезендә Россия Федерациясе гражданы я чит ил гражданы территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документ яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкача каралмаган булса, җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклы чит ил гражданы;

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Федераль законның үз кеченә керүен исәпкә алып, 2021 елның 1 июленнән үз кеченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Парфилова Н.В.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов